Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты каршындагы укыту-методик берләшмәсе карары белән 04.05.2017 расланды

Беркетмә №2

Рәис_______________Р.Р.Бәдриева

# ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ КОНЦЕПЦИЯСЕ

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татар телен һәм татар әдәбиятын укыту концепциясе (алга таба – Концепция) Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең субъектлары, шулай ук чит илләрдәге белем бирү оешмаларында татар телен, татар әдәбиятын укытуны камилләштерүнең нигез принципларына, максатлары һәм бурычларына, төп юнәлешләренә бөтенлекле карашлар системасын тәшкил итә.

Документ татар теленең:

– Россиядә сан ягыннан икенче милләт булган, күбесенчә Татарстан Республикасында, һәм шулай ук Россия Федерациясенең күп кенә субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә бергә тупланып (компактлы) яшәүче татарларның туган теле булуын;

– Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр» Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсе статусына ия икәнлеген исәптә тотып эшләнде.

Концепция тел сәясәте һәм мәгариф өлкәсендә федераль һәм республика Законнарына, гомумевропа стандартлары һәм тәкъдимнәренә туры китереп, 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү концепциясен исәпкә алып әзерләнде.

Бүгенге көнгә Россия Федерациясендә туган телне һәм дәүләт телләрен саклау һәм үстерү өчен кирәкле норматив-хокукый база булдырылган, Татарстан Республикасында тиешле оештыру-идарә итү, фәнни-методик, кадрларга кагылышлы шартлар тудырылган. Кабул ителгән норматив документларга ярашлы рәвештә татар теле һәм татар әдәбияты гомуми белем бирү системасында туган тел һәм туган телдәге әдәбият һәм шулай ук дәүләт теле һәм чит телле әдәбият буларак мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү оешмаларының 1-11 сыйныфларында өч юнәлештә өйрәнелә:

– гомуми белемне татар телендә бирүче оешмаларда татар теле һәм татар әдәбияты (татар укучылары өчен);

– гомуми белемне рус телендә бирүче оешмаларда татар теле һәм татар әдәбияты (татар укучылары өчен);

– гомуми белемне рус телендә бирүче оешмаларда татар теле һәм татар әдәбияты (рус телле укучылар өчен).

Һәр юнәлеш буенча үрнәк эш программалары төзелгән, УМКлар эшләнгән; татар теле һәм татар әдәбияты укытучыларын әзерләү тормышка ашырыла; педагогларга өстәмә һөнәри белем бирү эше оештырылган.

Татар теле һәм татар әдәбиятын укытуның концептуаль нигезләрен яңарту гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларының предмет өлкәләрен камилләштерү (модернизацияләү) кысаларында алып барыла һәм Россия Федерациясендә мәктәптә филологик белем бирүдә соңгы еллардагы үзгәрешләрне исәпкә ала. Әлеге Концепция нигезендә татар телен һәм татар әдәбиятын укыту ике юнәлештә гамәлгә ашырыла:

– туган тел буларак татар теле һәм туган телдәге әдәбият буларак татар әдәбияты (татар укучылары өчен);

– дәүләт теле буларак татар теле һәм чит телдәге әдәбият буларак татар әдәбияты (рус телле укучылар өчен).

Концепцияне тормышка ашыру белем бирү барышының барлык этапларында татар теле һәм татар әдәбиятын укытуның эчтәлеген камилләштерүгә, аны төбәк мәгарифенең аерылгысыз өлеше буларак карап, татар теле һәм татар әдәбиятын укытуның белем бирү, тәрбияви һәм үстереш потенциалын арттыруга юнәлдерелгән.

## II. Хәзерге заман белем бирү системасында «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» предметларының әһәмияте

Татарстан Республикасы территориясендә татар теле һәм татар әдәбияты мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү, урта һөнәри һәм югары белем бирү баскычларында өйрәнелә. Гамәлдәге хокук системасы һәм норматив актлар белән ярашлы рәвештә татар теле һәм татар әдәбияты гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларында билгеләнгән «Туган тел һәм Туган телдәге әдәбият» предметы кысаларында өйрәнелә һәм белем бирү программасында уку-укыту планының үзгәрешсез (инвариант) өлешенә кертелгән, республика укучыларының барысы өчен дә мәҗбүри булып санала.

Татар телен туган тел буларак укыту татар теленең саклануын һәм үсешен тәэмин итә, татар халкына аны функциональ куллану шартларын һәм мөмкинлеген тудыра, ил гражданнарының конституция нигезендә туган телдә белем алуга булган хокукын тәэмин итә. Туган тел буларак татар телен укыту туган телдә иркен сөйләшә һәм яза алуга, аны төп аралашу чарасы кебек кабул итүгә, милли әхлакый-этик нормаларны үзләштерүгә, туган телнең эстетик кыйммәтенә төшенүгә; татар теленең төзелеше, системасы хакындагы белемнәрне һәм аның кулланылыш кагыйдәләрен үзләштерүгә, шулай ук әлеге телдә аралашучы менталитетын формалаштыруга, милли-мәдәни үзбилгеләнүгә, телнең аралашу вазифасына таянып халыкның этник мәдәнияте турында белем алуга, татар әдәби сөйләм нормаларына өйрәтүгә юнәлтелгән.

Россия Федерациясенең этномәдәни татар компоненты булган субъектларында татар теле мәктәптә белем бирүнең барлык баскычларында, үрнәк төп белем бирү программаларына таянып мөстәкыйль формалаштырыла

торган эш программаларына нигезләнеп, гомуми белем бирү оешмаларының белем бирү программасына туры китереп туган тел буларак укытыла.

Дәүләт теле буларак татар теле укучыларда сөйләм эшчәнлегенең төп төрләрендә аралашу (коммуникатив) компетенцияләре формалаштыру, телдән һәм язма сөйләм культурасы нигезләрен үзләштерү, укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп, аралашуның төрле очракларында татар телен куллану осталыгын арттыру һәм күнекмәләр булдыру, күпмәдәниятле җәмгыятьтә үзара татар телендә аңлашу мөмкинлеге формалаштыру максаты белән укытыла.

Татар әдәбияты гуманитар белем бирүдәге шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсеш дәрәҗәсен билгеләүче төп предметлардан санала. Ул тормышны танып белү һәм чынбарлыкны кабат тергезү чараларының берсе булып тора – сәнгатьле тасвирлау алымнары ярдәмендә әдәби дөнья сурәте барлыкка китереп, ул аңа карата билгеле бер мөнәсәбәт тудыра; эмоциональ тәэсир итү көченә ия.

Әдәби белем бирү китап укуның һәм үзенең алга таба шәхсән үсеше өчен әдәбиятның әһәмиятен аңлаган, үз фикерен дәлилләргә сәләтле һәм аны телдән дә, язмача да тәгъбир итә белгән квалификацияле китап укучы тәрбияләү; тормышны һәм үз-үзен танып белү, кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен килештерү чарасы буларак та яшь кешедә даими китап укуга ихтыяҗ формалаштыру белән бәйле.

Туган телдәге әдәбият буларак укытылганда ул мөһим милли-мәдәни кыйммәтләрне, фикер-карашларны, рухи-әхлакый күзаллауларны үзендә туплап, татар халкының тормыш фәлсәфәсен аңлау һәм үзләштерүгә, милли үзаң һәм үзбилгеләнү калыплашуга китерә, шулай ук гомумроссия гражданины буларак формалашуга да ярдәм итә. Аны өйрәнү эстетик зәвык, сәнгати фикерләү, әйләнә-тирә дөньяны эмоциональ-кыйммәти күрү, иҗади күзаллау үсешен тәэмин итәргә тиеш.

Чит телдәге әдәбият буларак ул татар халкының тарихи-мәдәни мирасы һәм рухи-эстетик кыйммәте кебек күзаллана, аны өйрәнү төрле этномәдәни традицияләрне чагылдыра торган әдәби әсәрләрне аңлау сәләтен үстерүгә юнәлтелгән. Классик һәм хәзерге татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре, танылган язучыларның тормыш юлы һәм иҗаты турындагы материаллар, тарихи-әдәби барыш һәм татар әдәбиятының милли үзенчәлекләре белән таныштыру, башка милләт вәкилләренә толерантлык һәм ихтирамлы мөнәсәбәттәге, татар халкының тарихы, мәдәнияте, фәлсәфәсе хакында күзаллаулары булган, һәр яктан камил шәхес тәрбияләүгә ярдәм итә.

Мәктәптә укытыла торган «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» предметлары үзара тыгыз бәйләнештә. Татар әдәбиятын туган телдәге әдәбият буларак укыту татар телен туган тел буларак өйрәтү белән килештерелә.Татар телен дәүләт теле буларак укыту татар әдәбиятын чит телдәге әдәбият буларак укыту белән бергә алып барыла.

## III. Концепциянең максаты һәм бурычлары

Бу Концепциянең максаты – татар теле һәм әдәбиятын укытуны дәүләт һәм җәмгыять куйган заман таләпләре белән тәңгәлләштереп, филологик һәм педагогик белем бирүгә яңача якын килү нигезендә камилләштерү.

Шушы рәвештә татар телен һәм әдәбиятын укытуның нәтиҗәлелеген арттыру өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү күздә тотыла:

1) һәр юнәлеш һәм телне үзләштерү дәрәҗәсе өчен предметлар эчтәлегенең фундаменталь төшен, лексик-грамматик, коммуникатив нормаларын (минимумнарын), мәҗбүри, өстәмә һәм мөстәкыйль уку өчен тәкъдим ителәчәк әдәбият исемлекләрен эшләү;

2) яңа үрнәк эш программалары, укыту-методик комплектлары, тел компетенцияләрен бәяләү системасын әзерләү, сынап карау (апробацияләү) һәм кулланылышка кертү;

3) баланың яшенә һәм кызыксынуына, аның туган тел яки дәүләт телен үзләштерү дәрәҗәсенә туры килгән, барыннан да элек, телдән дөрес сөйләмгә алып чыга торган, аралашу компетенцияләрен формалаштыруны күздә тоткан нәтиҗәле технологияләрне гамәлгә кертү;

4) татар филологиясе өлкәсендә заман таләпләренә җавап бирә торган педагог-хезмәткәрләр һәм фәнни кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм белемнәрне күтәрү системасын камилләштерү;

5) татар телен һәм әдәбиятын укытуның сыйфатын күтәрү, методик яктан ныгыту, муниципаль һәм мәктәп эчендәге мониторинг ярдәмендә идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру;

6) татар телен һәм татар әдәбиятын укытуның норматив-хокукый нигезен камилләштерү;

7) Татарстан Республикасыннан читтәге белем бирү оешмаларына булышу һәм аларга методик ярдәм күрсәтү.

## IV. Татар телен һәм татар әдәбиятын өйрәнү һәм укыту өлкәсендәге проблемалар

Белем бирү оешмаларында татар телен һәм татар әдәбиятын системалы өйрәнүнең күп еллык традицияләре (методик юнәлешләр, укыту-методик комплектлары, фәнни-педагогик мәктәпләр һәм белем бирү практикалары) илебездәге мәгариф системасының мөһим потенциалын тәшкил итәләр. Шуның белән бергә, татар телен һәм татар әдәбиятын укыту методикасы аралашуга, шәхесне үстерүгә юнәлтелгән якларга ныграк игътибар итеп, дидактик яктан

үзгәрешләр һәм федераль дәүләт белем бирү стандартлары (ФДББС) нигезендә камилләшүне таләп итә. Татар телен һәм татар әдәбиятын өйрәнү һәм укыту өлкәсендә күзәтелә торган проблемаларны түбәндәге төп төркемнәргә берләштерергә мөмкин.

### 4.1. Мотивлаштыру белән бәйле проблемалар

Хәзерге вакытта көндәлек тормыш өчен филологик белемнең әһәмиятен тиешенчә бәяләмәү белән бәйле, мотивлаштыру характерындагы берничә проблема күзгә ташланып тора. Укучылар арасында татар телен өйрәнүгә кызыксынуның кимүе, иң беренче чиратта, уку-укыту программасының катлаулылыгы, дәреслекләрдә грамматик материалның өстенлек итүе, балаларның яшь үзенчәлекләренә бөтенләй ук туры килмәгән белем бирү технологияләрен кулланудан килеп чыга. Гамәлдә бу укучыларда чагыштырмача җиңеләйтелгән программа буенча татар телен дәүләт теле буларак өйрәнә торган төркемнәргә күчү теләге уянуга китерә.

Төп һәм урта мәктәптә мотивлаштыру мәсьәләләре әлеге предметлар буенча дәүләт йомгаклау аттестациясенең булу (булмавы) белән дә билгеләнә. Мәҗбүри имтиханнар теге яки бу предметка җитди һәм җаваплы карау өчен мөһим стимул (этәргеч) бирә. Әлеге мәсьәлә федераль дәрәҗәдә хәл итүне сорый. Халыкара нормаларга туры китереп, туган телдә белем бирү компетенциясе төп һәм мәҗбүри компетенциягә әйләнергә тиеш.

Төп һәм урта мәктәптә укытуның нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү өчен, предмет буенча тирәнтен теоретик белем бирү бурычы белән бергә, укучыларда туган телгә кызыксыну һәм аны телдән дә, язмача да аралашуда аңлап һәм урынлы куллануга теләк уятуга, шулай ук заманча технологияләр мөмкинлекләрен дә файдаланып, татар халкының мәдәнияте белән аерылгысыз бәйләнешне дә саклаган хәлдә телнең психолингвистик үзенчәлекләренә күбрәк игътибар бирергә кирәк.

Татар әдәбияты дәресләрендә уку-укыту эшчәнлегенең төп төре булып әсәрне анализлау (тикшерү), әсәр, автор һәм әдәби барыш турында тарихи-мәдәни мәгълүмат белән танышу, әдәби анализ өчен кирәкле төшенчәләрне үзләштерү тора. Бу мөһим аналитик, шәрехләү эшчәнлеге әдәби әсәрне җентекләп уку һәм тирәнтен аңлаудан соң башкарылса гына нәтиҗәле була. Уку өлеше еш кына күзәтү һәм контрольдән читтә калып, татар әдәбиятына кызыксыну кимүенең сәбәбенә әйләнә.

Әлеге ситуация уку-укыту программасының күләме зур булу сәбәпле уку вакытының җитмәвенә дә бәйле. Укучылар әсәрләрне, игътибарны төп моментларга гына юнәлтеп, әдәби текстта төрле тасвири моментларны төшереп калдыру исәбенә йөгерек уку ярдәмендә үзләштерергә тиеш булалар.

Җитди сәбәп укытучы шәхесенә дә бәйле. Укучыны әңгәмәдәш кебек кабул итү зарур, укытучының үзенә дә әдәбиятны укыту, әсәр хакында укучы белән фикерләшү кызыклы булырга тиеш. Нәкъ менә укытучы укучыларын үз артыннан үзенчәлекле әдәбият дөньясына алып кереп китә ала.

Татарстан Республикасында ике дәүләт телендә дә сөйләшүче гражданнарны исәпкә алу, стимуллаштыру һәм бәяләүнең юклыгы татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә мотивацияне формалаштыру юлында төп чишелмәгән проблема булып кала. Бүген филологик белем бирү татар телен өйрәнүгә эчке мотивация эзләү, балалар һәм яшүсмерләрне әдәбиятка тартырлык, классик һәм хәзерге әдәбиятның иң әһәмиятле әсәрләренә кызыксыну уятырлык дәлилләр табу һәм шундый методикалар булдыру кирәклеген күрсәтте.

## 4.2. Эчтәлеккә кагылышлы проблемалар

Татарстан Республикасы мәктәпләрендә татар теле һәм татар әдәбияты барлык укучыларга да 1992 елдан башлап укытылуга карамастан, бүгенге көндә дә татар балаларының да, рус телле балаларның да тәкъдим ителгән материалны үзләштерүләре белән бәйле бик күп проблемалар яшәп килә.

Белем бирүдә җитди кимчелекләргә китерә торган сәбәпләрнең берсе булып уку-укыту материалында логик эзлеклелекнең бозылуы тора. Дәвамчанлык, системалылык һәм дифференциальлек мәсьәләсен хәл итү гомуми һәм һөнәри белем бирүнең барлык баскычларында да өзлексез белем бирү системасын тудырырга ярдәм итәчәк.

Татар балаларына татар телен өйрәтүнең ахыргы максаты – иҗтимагый күренеш буларак тел турындагы белемнәрне, тел күренешләрен һәм фактларын тикшерү күнекмәләрен комплексны үзләштерү, телнең үз байлыгы һәм татар халкының мәдәнияте, аралашу өлкәсендәге социаль-мәдәни стереотиплар турындагы, шулай ук милли-мәдәни мәгънәгә ия тел берәмлекләре һәм шуның нигезендә коммуникатив культура, милли үзаң формалаштыруга кагылышлы күзаллау булдыру. Әмма хәзерге вакытта әлеге максат ачыклап куелмаган.

Татар телен туган тел буларак өйрәтү лингвистик компетенция формалаштыруга юнәлтелгән булырга тиеш. Ләкин уку-укыту предметының катлаулылыгы һәм күләм ягыннан зурлыгы үзләштерелгән лингвистик материалның мәктәпне тәмамлаучылар телендә һәм сөйләмендә тулы рәвештә чагылыш табуына комачаулый. Бу хәл укучыларда аралашу күнекмәләрен формалаштыруга һәм татар телен туган тел буларак укытуга метапредмет югарылыгыннан якын килүгә, татар теленең татар мәдәнияте һәм тарихы өлкәсенә караган башка гуманитар дисциплиналар белән якынаюына тиешле дәрәҗәдә игътибар бирелмәү белән аңлатыла.

Кызганычка каршы, рус телендә белем бирүче мәктәпләрне тәмамлаучыларның барысы да телдән һәм язма сөйләм күнекмәләренә, әдәби тел нормалары һәм сөйләм этикетына ия була алмый. Татар телен дәүләт теле буларак укыту күнекмәләрне телдән һәм язма сөйләмдә куллана алырлык аралашу (коммуникатив) компетенциясен формалаштыруга юнәлдерелгән булырга тиеш. Әмма УМКларның күптөрлелеге һәм аларда һәр үзләштерү дәрәҗәсе өчен бердәм расланган лексик һәм грамматик нормаларның булмавы, материалны җиңел аңлатырлык мультимедиа чараларының җитмәве, дәвамчанлыкны һәм системалылыкны бозу ахыргы нәтиҗәгә ирешүдә каршылык тудыра.

Күрсәтелгән сәбәпләр планлаштырылган нәтиҗәләрне һәм куелган максатка ирешү механизмнарын конкрет һәм төгәл күз алдына китереп, белем бирү барышының барлык баскычларында һәм төркемнәрендә татар телен укытуга комплекслы якын килүнең зарурлыгын күрсәтә.

Әдәби белем, нигездә, ике башлангычны берләштерә: мәгълүмат җиткерү (биографик, әдәби-тарихи, теоретик материал белән таныштыру) һәм уку. Гамәлдә беренчесе өстенлекә ия булып чыга. Әмма бары тик уку гына укучыны алдагы буыннарның рухи тәҗрибәсенә нәтиҗәле һәм отышлы якынайту көченә ия.

Әдәби белем бирү эчтәлегендә әсәрләрне кабул итү һәм шәхси бәя бирү күнекмәләрен формалаштыруга җитәрлек игътибар ителми. Укучыларны сәнгатьнең бер төре буларак матур әдәбият дөньясына алып керү өчен китапханәләр, музейлар, театрларның үзенчәлекле мөмкинлекләрен куллану, төрле мәдәни һәм белем бирү-агарту оешмалары хезмәткәрләренең бергәләп эшләвенә ирешү кирәк. Болар гомуми белем бирү мәктәбе өчен татар әдәбияты программаларында, УМКларда, дәреслекләрдә билгеләнергә тиеш.

XX-XXI гасырлар чигендә укучыларның тормыш тәҗрибәсе, әхлакый күзаллаулары һәм өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эчтәлеге арасында өзеклек барлыкка килде. Уку-укыту программасының классиканы өйрәнүгә йөз тотуы хәзерге татар әдәбиятын арткы планга чигерә. Укучының яшь үзенчәлегенә бәйле текстны психологик кабул итү мөмкинлеге һәм әсәрнең катлаулылыгы да еш кына бер-берсенә тәңгәл килми. Шушы Концепциядә куелган максатларны исәпкә алып, әдәби материалны фәнни нигезләп сайлап алу сорала.

Үсеп килүче буынның татар әдәбиятыннан читләшүенә еш кына дәреслекләргә һәм хрестоматияләргә кертелгән текстларның мәктәп укучысы өчен яраклаштырылмаган, аңлатмаларсыз һәм тиешле шәрехләүләрсез бирелүе үзе үк сәбәп булып тора. Укучыларның сөйләм тәҗрибәләренең һәм әдәби әсәрләр теленең бер-берсенә тәңгәл килмәве аерым сүзләрнең мәгънәләрен, грамматик формаларны һәм категорияләрне белмәүдә, әсәрләрдә сурәтләнгән аерым тормыш ситуацияләренең мәгънәсен аңлаумауда, билгеле бер фактларны, шул исәптән тарихи фактлар, йола һәм гадәтләрне белмәүдә чагылыш таба.

Туган телле әдәбият буларак татар әдәбияты курсы укучыларда татар халкының үткәне белән горурлану хисе тәрбияләү, милли традицияләрне, милли геройларны белү һәм хөрмәт итү, дөньяга караш, менталитет, фәлсәфә, татар матди һәм рухи мәдәниятенең үзенчәлекләрен күрсәтү аша милли үзбилгеләнүгә алып бару максатыннан камилләштерүне сорый. Татар әдәбияты әсәрләре тарихи-мәдәни ретроспективада милли идеягә берләшә торган мегатекст тәшкил итәләр. Бу һәр милли мәдәнияткә хас, һәм шуны аңлау туган телдәге әдәбият буларак татар әдәбиятын укыту нигезенә салынган булырга тиеш.

Чит телдәге әдәбият буларак татар әдәбияты эчтәлегендә, беренче чиратта, татар телендәге әдәби текстны аңлау дәрәҗәсе исәпкә алыну шарт. Бу укучыларның яшь һәм әдәби үсеш үзенчәлекләре таләпләренә җавап бирә торган аңлаешлы, кызыклы, адаптацияләнгән текстлар сайлауны таләп итә. Моннан тыш, махсус әзерлексез генә чит телле әдәбиятны кабул итү, башка әдәби дөньяга, чит

образлар системасына керү дә бик авыр. Шуңа күрә чит телле әдәбият буларак татар әдәбиятын өйрәнү барышында дөнья әдәбияты белән ассоциатив бәйләнешләр урнаштыру, рус һәм татар әдәбиятларының уртак якларына таяну мөһим санала.

## 4.3. Методика өлкәсендәге проблемалар

«Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» предметлары гомуми һәм махсус компетенцияләр формалаштырырга тиешләр. Әлеге предметларны укыту барышы методик яктан һәм белем бирү эшчәнлеген оештыру ягыннан төрле эш формаларын куллануны күздә тота. Бу татар телен укытуның үз методикасын, үзебезнең һәм гомумевропа лингвометодикасының тәҗрибәсенә таяна торган, дөньякүләм кабул ителгән фәнни стандартларга җавап бирерлек укучыларның белемнәрен бәяләү системасы булдыруны таләп итә. Шуңа бәйле рәвештә татар телен туган тел буларак укытканда шушы юнәлешнең максат-бурычларына туры килә торган баскычлап укыту тәртибен эшләргә, төрле яшь категорияләре өчен лексик-грамматик минимумнар расларга, укучыларның мөстәкыйль белем алуга омтылышын һәм белем бирү оешмаларында тел мохитен саклауда актив катнашуын стимуллаштыру юлларын табарга кирәк. Шул рәвешле, тел буенча белем бирү парадигмасы телне фәнни яктан һәм аның төзелешен өйрәнүдән – аралашу һәм шәхси үстерелеш чарасы, этник мәдәниятне саклаучы һәм киләчәк буыннарга тапшыручы буларак өйрәнүгә таба борыла.

Дәүләт теле буларак татар телен укытуны укучылар башка мәдәниятне дөрес кабул итәрлек, яшәп килүче стереотипларга аңлап якын килерлек, мәдәниятара багланышларның төрле очракларына шәхси мөнәсәбәт формалашырлык итеп оештырырга кирәк. Укытуны коммуникатив-эшчәнлекле, мәгълүматлы, эчтәлекле, кызыклы итү, укучыларда татар теленә кызыксыну тәрбияләү, укытуның нигезе буларак татар телендә аралашу өчен кирәкле сөйләм минимумы булдыру мөһим. Алга таба индивидуаль белем алу юнәлешләрен формалаштыру юлы белән баскычлап укыту системасы кысаларында укучыны кызыксындыру өчен тизләтелгән белем бирү формаларын эшләү дә көтелә.

Укучыларга телне өйрәтүдә мәгълүмати-аралашу технологияләрен файдалануны көчәйтергә һәм киңәйтергә, кирәкле дидактик материалларны, электрон сүзлекләрне, хрестоматияләрне, уен-тренажерларны, татар теле һәм әдәбияты буенча ОГЭ (ТДИ) һәм ЕГЭ (БРИ) ларга әзерләү өчен кулланмаларның ачык банкларын, олимпиада биремнәренең ачык банкларын булдыру таләп ителә.

Әдәби белем бирү укучыларда чагыштыра, гомумиләштерә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгели алу; планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, диалоглар һәм монологлар төзү, мөстәкыйль сораулар куя белү, үз фикерләрен дөрес тәгъбир итә һәм дәлилли белү һ.б. күнекмәләр белән бәйле универсаль уку гамәлләрен формалаштыруны күздә тота. Ләкин бүген универсаль уку гамәлләренең әһәмиятен, шулай ук аларны, аеруча чит телле әдәбият буларак татар әдәбиятын укыту вакытында, җитәрлек дәрәҗәдә формалаштыру кирәклеген аңлап бетермәү күзәтелә. Шуңа күрә гомуми белем бирү мәктәбендә татар

әдәбиятын укыту методикаларында һәм технологияләрдә гамәли юнәлешкә аерым игътибар бирү сорала.

Тел буенча да, әдәби белем бирү практикасында да уен, иҗат итү, аралашу эшчәнлегенә нигезләнгән, укучыларны мәгълүмат тупларга һәм план, тезис планы, конспект, доклад әзерләү, аннотация, инша, эссе, әдәби-иҗади текст язу, алдан игълан ителгән темага проект эшләү өчен кирәк булган материалларны эшкәртергә өйрәтү; мәгълүмати кырда ориентлаша алу: энциклопедияләр, сүзлекләр, белешмәлекләр, махсус әдәбият белән эшли белү күнекмәләре; китапханәләр каталоглары, библиографик күрсәткечләрне, Интернетта эзләнү системасын файдалану мөмкинлеге биргән технологияләр тиешле дәрәҗәдә кулланылмый.

Методик характердагы проблемалар арасында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны укытуны оештыру белән бәйле булганнарын да: инклюзив белем бирү кысаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләү өчен кадрларның әзерлекле булмавы; татар теле һәм татар әдәбиятыннан укыту-методик әсбапларның җитмәве, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен кирәк булган хрестоматияләр, электрон текстларның юклыгын – аерып билгеләү шарт.

Сәламәтлеклеге, мөмкинлеге чикле булган балаларга инклюзив белем бирү процессын оештыруга махсус якын килү таләп ителә. Яңа ысуллар һәм технологияләр куллану һәр укучыга белем бирү барышында аларның сәләтен үстерү, танып белү ихтыяҗларын канәгатьләндерү, шәхси компетенцияләрне үстерү өчен шартлар булдыруны күздә тотарга тиеш. Инклюзив белем бирүгә иң туры килгән технология булып «портфолио» технологиясе тора. Ул дифференциаль якын килүне сыйфатлы һәм нәзакәтле итеп башкарырга, уку-укыту процессын индивидуальләштерүне укучыларның акыл, физик мөмкинлекләрен исәпкә алып, аларның игътибарын моңа юнәлтмичә, «чикләнгән мөмкинлекләрен» артык басым ясамыйча гына тормышка ашыру юлын билгели.

## 4.4.Кадрлар әзерләү өлкәсендәге проблемалар

Фәнни һәм педагогик кадрларны әзерләү һәм аларның белемен күтәрү мәсьәләләрен шартлы рәвештә түбәндәгечә төркемләргә мөмкин.

Беренчедән, мәктәпне тәмамлаучылар арасында аеруча сәләтле булганнары укытучылар хәзерли торган «Педагогик белем бирү. Туган тел һәм әдәбият» юнәлешендәге югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларына укырга килмиләр. Сәләтле балаларны түбән сыйныфлардан ук бу һөнәргә җәлеп итү эшен көйләү, профиль буенча урта һөнәри һәм югары уку йортларына мәктәпне тәмамлаучыларның яхшы укый торганнарын кызыксындыру сорала.

Россия Федерациясенең татарлар бергә тупланып яшәгән субъектларында, Татарстан, Башкортстан һәм Мордовия республикаларын исәпкә алмаганда, татар теле укытучыларын әзерләү туктатылган. Соңгы елларда Россия регионнарыннан Татарстан югары уку йортларына татар филологиясе юнәлешләренә укырга керүчеләр саны елдан-ел кими бара. Татарстан Республикасында яшәп югары уку

йортларын тәмамлаучылар да эш урыны һәм яшәү урыны буларак Россия Федерациясе субъектларын сайламыйлар.

Икенчедән, Россия Федерациясе субъектларында урта һөнәри белем бирү дәрәҗәсендә, Татарстан Республикасын исәпкә алмаганда, татар балалары белән эшләү өчен тәрбиячеләр һәм башлангыч сыйныф укытучыларын әзерләү алып барылмый. Шул рәвешле, Россия Федерациясенең татарлар бергә тупланып яшәгән субъектларында мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына һәм башлангыч мәктәпкә тәрбия һәм белем бирү процессын татар телендә алып барырга сәләтле яшь педагог-хезмәткәрләр килми. Шундый ук хәл югары мәктәп дәрәҗәсендә дә күзәтелә. Бүгенге көндә, бюджет урыннары булмау сәбәпле, илнең югары уку йортларында тиешле факультетлар, бүлекләр һәм кафедралар берләштерелә.

Өченчедән, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының белемнәрен күтәрү, һәм шулай ук аттестацияләү системасында чишелмәгән проблемалар бар. Россия Федерациясенең татарлар бергә тупланып яшәгән күпчелек субъектларында татар теле һәм әдәбияты укытучыларының белемнәрен күтәрү өчен темалар һәм төркемнәр формалаштырылмый. Шулай ук Татарстан Республикасында укытучыларның белемнәрен күтәрүне тормышка ашыручы оешмаларның барсында да заман таләпләренә җавап бирерлек программа һәм методикалар эшләнмәгән. Бу педагогның һөнәри осталыгына формаль таләпләрне үзгәртүнең дә, һөнәри үсештә ярдәм итәрлек чаралар системасын гамәлгә кертүнең зарурлыгын да күрсәтә. Гомумән алганда, белем күтәрү программаларын яңарту, педагогларның һөнәри осталыкларын камилләштерүнең альтернатив формаларын кертү, аларның үзлексез һөнәри үсешләрен стимуллаштыра торган механизмнарны эшләү сорала. Бу грантлар ярдәме, һөнәри конкурслар һәм олимпиадалар, башка чаралар булырга мөмкин. Моннан тыш, аттестациянең үстерелешле потенциалы җитәрлек дәрәҗәдә файдаланылмый, бу турыда әлеге процедураны үткән укытучыларның һөнәри-шәхси үсеше күзлегеннән чыгып ясалган анализлар күрсәтеп тора. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларын аттестацияләү тәртибен яңартырга, муниципаль һәм республика дәрәҗәсендә хезмәттәшләре алдында методик җитлеккәнлекләрен раслаган укытучыларга аттестацияне үтүнең альтернатив юлын булдыруны да карарга кирәк.

Дүртенчедән, милли кадрлар әзерләүгә дәүләт заказын формалаштыруның нәтиҗәле механизмы эшләнмәгән булу һәм бу өлкәдә системасызлык эшне оештыруда проблемалар тудыра һәм белем бирүнең сыйфатын түбәнәйтүгә китерә. Мәсәлән, күп еллар дәвамында татар теле укытучыларын башлангыч, төп, югары мәктәп баскычларында эшләү өчен дифференциаль әзерләү булмады дияргә мөмкин. Бу татар телен башлангыч мәктәптә дә, югары сыйныфларда да укыта торган укытучыларга билгеле бер кыенлыклар тудырды һәм аларның эш сыйфаты күрсәткечләрендә чагылыш тапты.

Каршылык тудыра торган фактор буларак Россия Федерациясенең субъектларында татар телен һәм әдәбиятын укытуга кадрлар һәм методик ярдәмнең җитмәвен билгеләп үтми калырга ярамый.

## V. Концепцияне тормышка ашыруның төп юнәлешләре

### 5.1. Гомуми юнәлешләре

Татар телен туган тел һәм дәүләт теле буларак укытуның концептуаль нигезләрен эшләгәндә мәгариф һәм тел белеме өлкәсендә рус һәм чит ил тәҗрибәсенә таяну мөһим. Аерым алганда, 2006 елның 18 декабрендә расланган «Европа Парламенты һәм Советы тәкъдимнәре» (2006/962/EC) кешенең бөтен тормышы дәвамында белем алу өчен кирәк булган төп компетенцияләр арасында мөһим һәм төп компетенцияләрнең берсе итеп туган телне белүне билгели. Бу хәзерге көндә һәр гражданинга, аралашу тәҗрибәсенә яки башка хәлләр һәм шартларга бәйсез рәвештә, үз туган телен өйрәнү һәм үстерү мөмкинлеген бирүгә юнәлдерелгән дәүләт мәгариф системасы аша туган телләрне саклау һәм үстерүнең әһәмиятен тагын бер тапкыр ассызыклый.

Татар телен һәм татар әдәбиятын укыту барышын камилләштерү күп очракта курсның эчтәлеген, уку-укыту контентын яңарту, татар телен һәм татар әдәбиятын укыту юнәлешләрен кабат карап чыгу, укыту методикаларын, укытучыларны хәзерләү һәм белемнәрен күтәрүне үзгәртү белән бәйле.

Туган тел һәм дәүләт теле буларак татар телен, туган телле әдәбият һәм чит телле әдәбият буларак татар әдәбиятын укыту барышын оештыру һәм яңа буын үрнәк программалар һәм УМКлар төзү нигез (база), тирәнтен өйрәнү (шул исәптән, олимпиадаларга әзерләү) дәрәҗәләрен күздә тотарга тиеш. Татар телен һәм татар әдәбиятын өйрәнү өчен укучыларның старт мөмкинлекләрен тигезләү башлангыч мәктәп этабында күздә тотыла.

Нигез дәрәҗәдә укучыларның татар теле һәм татар әдәбиятыннан белем-күнекмәләре әлеге өлкәләрдә белем алуны дәвам итәрлек булу шарт. Әлеге дәрәҗә аралашу күнекмәләре булдыруга, татар теле, татар әдәбиятының тарихы һәм теориясе, татар халык авыз иҗаты, татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләре турында нигез күзаллаулар һәм төшенчәләр формалаштыруга, әдәби текстны, язучы һәм шагыйрьләрнең иҗатларын, әдәби барышның төрле чорларында чагылыш тапкан төп тенденцияләрне аңлау, анализлау, шәрехләү һәм бәяләүгә юнәлеш тота, матур әдәбият укуга мәхәббәт тәрбияли.

Тирәнтен өйрәнү дәрәҗәсендә укучыларның татар теле, татар әдәбияты тарихы һәм теориясеннән белем-күнекмәләре филологик юнәлештә белем алуны дәвам итәрлек күләмдә булырга тиеш. Әлеге дәрәҗә татар тел белеме, татар әдәбитының тарихы һәм теориясе, халык авыз иҗаты буенча киңәйтелгән күзаллаулар һәм төшенчәләр формалаштыруга, сөйләм эшчәнлеге күнекмәләрен камилләштерүгә, милли-мәдәни эчтәлекле төп тел берәмлекләре турында системалы белемгә, татар әдәбиятының башка әдәбиятлар янәшәсендә структур,

сәнгати, эстетик үзенчәлекләрен, татар теленең дөнья фәне контекстында тарихи һәм функциональ үзенчәлекләрен билгеләүгә йөз тота.

Моның белән бәйле рәвештә түбәндәгеләрне эшләү сорала:

татар теле һәм татар әдәбиятыннан ике юнәлештә үрнәк программалар төзү:

– туган тел буларак татар теле һәм туган телдәге әдәбият;

– дәүләт теле буларак татар теле һәм татар (чит телле) әдәбияты.

Шул ук вакытта дәрәҗәләрнең төрлелеге программаларның компонентлылыгын таләп итә: алар нигез, тирәнтен һәм олимпиада дәрәҗәләрендәге уку-укыту материалыннан торачак;

татар теле һәм татар әдәбияты курсларының фундаменталь төшен, дифференциацияләү һәм индивидуальләштерү нигезендә төзелгән, укучыларның мөстәкыйль иҗади эшчәнлегенә өстенлек бирүгә күчешне күздә тоткан үрнәк программалар, яңа буын укыту-методик комплектлары (эш программасы, дәреслек, «укытучы өчен китап», электрон дәреслек (дәреслек сайты) әзерләү;

укучыларның күчеш һәм йомгаклау аттестацияләре өчен контроль үлчәү материаллары булдыру;

өстәмә (вариатив) материал исәбенә киңәйтелгән һәм үз эченә, әдәби әсәрләр текстларыннан тыш, аңлатмалар (шәрехләр), сораулар һәм биремнәрне алган хрестоматияләр төзү;

төрле типтагы заманча уку-укыту сүзлекләре эшләү;

җитәкчелек һәм профессор-укытучылар составына мәктәптә һәм вузда дәрәҗәләп белем бирүгә күчү өчен кирәкле шартлар булдыру.

## 5.2. «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» предметларының эчтәлеге

### 5.2.1. «Татар теле» предметы

Туган тел буларак татар теле гомуми белем бирү системасында татар теленнән белем-күнекмәләргә ия булуның түбәндәге дәрәҗәләрен күздә тота: хәзерлек, башлангыч, база (нигез), югары баскычлар.

Хәзерлек дәрәҗәсе мәктәпкәчә белем бирү баскычында баланың телне никадәр белүенә карап оештырыла һәм сөйләм теленә, хикәяләүгә (сөйләп бирүгә) өйрәтүгә; балаларның аваз культурасын үстерүгә, сөйләмнең грамматик дөреслегенә; әйләнә-тирә дөнья белән таныштыруга һәм сүзлек байлыгын арттыруга йөз тота.

Башлангыч дәрәҗә башлангыч белем бирү кысаларында тормышка ашырыла. Укыту дифференциаль якын килүгә нигезләнә һәм укучыларның туган тел буларак татар телен белүенең төрлелеген исәпкә ала. Укытуның эчтәлеге сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үзләштерүгә, татар теленең төзелеше һәм структурасы турында күзаллау формалаштыруга, туган телне милли-мәдәни феномен буларак аңлауга буйсындырыла.

База (нигез) дәрәҗәсе төп гомуми белем бирү баскычында гамәлгә ашырыла. Әлеге дәрәҗәнең эчтәлеге коммуникатив, лингвистик, этномәдәни

компетенцияләрне формалаштыруга һәм үстерүгә йөз тота. Укыту татар телен татар халкының төп милли-мәдәни кыйммәтләренең берсе буларак кабул итүгә; шәхеснең интеллектуаль, иҗади сәләтен һәм әхлакый сыйфатларын үстерүдә туган телнең әһәмиятен аңлауга; лингвистиканың төп төшенчәләрен үзләштерүгә; сүзлек байлыгын һәм телдән аралашу барышында фикерләрне һәм хисләрне ирекле рәвештә чагылдыру өчен кирәкле грамматик чараларның тиешле күләмен формалаштыруга; хәзерге татар әдәби теленең төп нормаларын үзләштерүгә; телнең төп берәмлекләрен һәм грамматик категорияләрен тану һәм анализлауга, телдән аралашу ситуациясенә туры китереп тел берәмлекләрен куллануга; татар теленең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләрен аңлау һәм аларны үз сөйләм практикасында куллануга юнәлдерелә.

Югары дәрәҗә урта гомуми белем бирү оешмаларында тормышка ашырыла һәм компетенцияләрнең барлык төрләрен лингвистик компетенциягә (телнең фонетик, лексик, грамматик һәм стилистик нормаларына) игътибар биреп камилләштерүне күздә тота. Бу баскычта татар телен укыту, туган телдә белем алуның нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү белән бергә, тел берәмлекләрен дөрес кабул итәргә һәм кулланырга өйрәтүне, туган телдә логик фикерләүне үстерүне; тел һәм мәдәният арасындагы бәйләнешләрне аңлауны; төрле темаларга иркен сөйләшә алу һәм фикерне ачык итеп җиткерә белү күнекмәләрен үзләштерүне; төп аралашу, белем алу һәм җәмгыятьтә кабул ителгән әхлакый-этик нормаларны үзләштерү чарасы буларак туган телнең вазифаларына төшенүне; туган телнең эстетик кыйммәтен аңлауны алга ала.

Телне үзләштерүнең югары, һөнәри һәм камил дәрәҗәләре хәзерге татар теле нормаларының барлык типларын үзләштерүне һәм коммуникатив эшчәнлекне камилләштерүне күздә тота. Әлеге дәрәҗәләр югары һөнәри белем бирү оешмаларында (хәзерләү юнәлешенә бәйле рәвештә) тормышка ашырыла.

Татар телен дәүләт теле буларак укыту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 19.01.2016 елда 22 номерлы Карары (Постановлениесы) белән расланган татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен бәяләү тәртибендә билгеләнгән түбәндәге дәрәҗәләрне үзләштерүне күздә тота:

1) элементар (CEFR буенча A 1 дәрәҗәсенә туры килә); 2) база (нигез) (A2); 3) урта (B1); 4) уртачадан югарырак (B2); 5) югары (C1).

Элементар этап татар телен үзләштерү дәрәҗәсенә бәйле рәвештә мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү этапларында тормышка ашырыла һәм актив лексика һәм татар этикеты формаларын үзләштерүгә йөз тота.

База (нигез) һәм урта дәрәҗәләр башлангыч һәм төп гомуми белем бирү кысаларында гамәлгә куела. Бу вакытта игътибар татар этикетының билгеле бер күләмдә аралашу өчен кирәк булган элементар формаларын аңларга һәм кулланырга өйрәтүгә, татар көнкүреше һәм мәдәни кыйммәтләр белән таныштыруга юнәлдерелә.

Урта дәрәҗәнең эчтәлеге тормышның төп сфералары белән бәйле аерым җөмләләрне һәм еш очрый торган гыйбарәләрне аңлау; таныш булган яки көнкүреш темаларга мәгълүмат алмашу белән бәйле аралашу; көндәлек тормышның төп аспектларын тасвирлау мөмкинлеге бирә торган сөйләм

осталыгына, күнекмәләрне үзләштерүгә йөз тота һәм төп гомуми белем бирү баскычында гамәлгә ашырыла.

Урта дәрәҗәдән югарырак дәрәҗә әдәби телдә типик темаларга ясалган конкрет чыгышларның төп идеяләрен аңлау; татар телле әңгәмәдәш белән аралашу барышында туа торган ситуацияләрнең күпчелегендә сөйләшүгә катнаша алу, таныш булган яки аеруча кызыксындыра торган темаларга бәйләнешле сөйләм төзү һәм шулай ук үз фикерләрен һәм киләчәккә планнарын дәлилле сөйли алуны колачлый. Татар телен белүгә карап төп һәм урта гомуми белем бирү кысаларында гамәлгә куела. Уртачадан югарырак дәрәҗәдә лингвистик компетенцияне үзләштерүгә дә игътибар бирелә: укучыларның фонетик, лексик, грамматик һәм стилистик тел нормалары буенча белем-күнекмәләре системалаштырыла.

Югары дәрәҗә түбәндәге осталык, күнекмәләрне үзләштерүне күздә тота: абстракт һәм конкрет темаларга, шул исәптән аерым белгечлеккә караган катлаулы текстларның гомуми эчтәлеген аңлау; һәм шул темаларга тоткарлыксыз ирекле сөйләм. Телне үзләштерүнең югары һөнәри һәм камил дәрәҗәләре югары һөнәри белем бирү оешмаларында (хәзерләү юнәлешенә бәйле рәвештә) тормышка ашырыла.

### 5.2.2. «Татар әдәбияты» предметы

Сыйфатлы әдәби белем бирү системасы тынычлык һәм иминлек нигезендә тизләнеп һәм тотрыклы үсешкә омтылган теләсә кайсы җәмгыять өчен мөһим. Мондый система төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-тарихи төшенчәләрне үзләштерүне, әдәби әсәр текстларын белүне, әдәби-тарихи барыш турында гомуми күзаллаулар формалаштыруны, әдәби-тарихи шартларны исәпкә алып һәм әдәби-теоретик төшенчәләр ярдәмендә әсәрләрне шәрехли һәм бәяли алуны; әдәби әсәрне кабул итү культурасын, автор позициясен аңлауны, образлы һәм аналитик фикерләүне, эстетик һәм иҗади сәләтләрне үстерүне; үз фикерләрен телдән һәм язмача дөрес аңлатып бирә белгән, белемнәрен системалаштыра һәм чынбарлык турында күзаллауны тәртипкә сала белгән грамоталы белгечләр әзерләүне; көндәлек тормышта һәм уку эшчәнлегендә матур әдәбият әсәрләре белән аралашу тәҗрибәсен кулланырга әзер, әхлакый, эстетик һәм интеллектуаль үскән шәхес тәрбияләүне; милли һәм гомумкешелек аңы, гражданлык позициясе, дөньяга толерант мөнәсәбәт формалаштыруны; мөһим гомумуку һәм универсаль уку гамәлләрен (танып белү максатын тәгъбир итү, планлаштыру, библиографик эзләнү, төрле чыганаклардан, шул исәптән Интернет челтәре аша кирәкле мәгълүматны табу һәм эшкәртә алу һ.б.) үзләштерүне тәэмин итәргә тиеш.

Әдәби белем бирү системасы дүрт үзара бәйләнгән этаптан төзелә: башлангыч дәрәҗә – әдәби уку; база (нигез) дәрәҗәсе – татар әдәбиятының теориясе һәм тарихы; урта дәрәҗә – бердәм барыш буларак татар әдәбияты тарихы; югары яки һөнәри дәрәҗә – татар әдәбият белеме (әдәбият теориясе, әдәбият тарихы, әдәби тәнкыйть).

Әдәби уку (татар әдәбияты) балаларны милли мохиткә алып керергә, татар балалар әдәбияты белән таныштырырга, китап укуга кызыксыну, әдәби текстны кабул итү культурасын формалаштырырга, үзенең кайсы милләт вәкиле булуын төшенү аша аңлы әхлаклылык һәм җаваплылык, патриотик хисләр, туган якка, Туган илгә мәхәббәт тәрбияләргә тиеш.

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә туган телдәге әдәбият буларак татар әдәбияты курсы милли үзаң һәм гражданлык җәмгыяте таләпләренә җавап бирә торган шәхси сыйфатлар тәрбияләү һәм үстерүгә юнәлтелгән, укучыларны татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләре, аерым язучыларның иҗаты белән таныштыруны, әдәби әсәрләрне анализлау һәм шәрехләү ысулларын үзләштерүне; аерым язучы һәм шагыйрьләрнең иҗатындагы яңалыкны күрергә, объектив нәтиҗәләр һәм мөнәсәбәт формалаштырырга өйрәтүне күздә тота.

Югары (10-11) сыйныфларда татар әдәбиятын туган телле һәм чит телдәге әдәбият буларак укыту программаларының эчтәлеге һәм структурасы нигезендә борынгы һәм урта гасырлардан башлап бүгенге көнгә кадәр өзлексез барыш буларак әдәбият тарихын үзләштерү концепциясе ята.

Татар әдәбият белемен үзләштерү әдәби белем бирүнең, грамоталы белгечләр хәзерләүнең йомгаклау баскычы буларак күзаллана.

Шулай итеп, татар әдәбиятын туган телле әдәбият буларак укыту түбәндәге тәртипне күздә тота:

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында – хәзерлек;

башлангыч белем бирүдә – башлангыч (әдәби уку);

төп гомуми белем бирүдә – база (нигез) (татар әдәбиятының теориясе һәм тарихы);

урта гомуми белем бирүдә – югары (өзлексез барыш буларак татар әдәбияты тарихы);

урта һәм югары һөнәри белем бирү оешмаларында (хәзерләү юнәлешенә бәйле рәвештә) – югары һәм һөнәри (татар әдәбият белеме).

Татар әдәбиятын чит телдәге әдәбият буларак укыту, беренче чиратта, татарча әдәби текстны аңлауга алып килергә тиеш. Моннан тыш, укучыларның үз фикерләрен телдән һәм язмача дөрес итеп җиткерә белүе, милли һәм гомумкешелек күзаллавы, гражданлык позициясе, тормышка толерант мөнәсәбәт һ.б. формалаштыру мөһим булып санала. Ул түбәндәге дәрәҗәләрне күздә тота:

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында – хәзерлек;

башлангыч һәм төп гомуми белем бирүдә – башлангыч (әдәби уку форматында);

урта гомуми белем бирүдә – база (нигез) (татар әдәбиятының теориясе һәм тарихы);

урта һәм югары һөнәри белем бирү оешмаларында (хәзерләү юнәлешенә бәйле рәвештә) – югары һәм һөнәри.

## 5.3. Мәктәпкәчә белем бирү

Мәктәпкәчә яшь телне өйрәтүдә иң нәтиҗәле чор булып санала. 7 яшькә кадәр балаларда акрынлап интуитив-гамәли юнәлеш базасында формалаша торган аралашу компетенциясе нигезләре үсә бара. Шуңа күрә мәктәпкәчә белем бирү оешмасында үстерешле укыту баланың потенциаль мөмкинлекләренә һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алган «якындагы үсеш зонасы»на юнәлгән булырга тиеш. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында сөйләмнең татар телендә оештырылуына ярдәм итә торган аралашу мохитен тудырырга кирәк. Мәктәпкәчә яшьтә татар телен өйрәнүдә төп бурыч булып татарча сөйләм телен үзләштерү өчен кирәкле башлангыч белем-күнекмәләр формалаштыру тора. Укыту барышында балалар татар сөйләмен ишетеп кабул итәргә һәм аңларга, аңлаешлы тематика, үзләштерелгән сүзләр ярдәмендә татарча сөйләшергә өйрәнергә тиешләр.

Мәктәпкәчә белем бирү программасы татар телен туган тел һәм дәүләт теле буларак башлангыч һәм дәвам итүче төркемнәрдә укытуны тәэмин итә. Татар телен туган тел буларак өйрәнү вакытында сөйләм үстерү дәресләре үткәрелә; белем бирү тулаем татар телендә бара; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнгән вакытта әлеге процесс аерым дәресләр формасында да, режим моментларны кулланып та тормышка ашырылырга тиеш.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында татар теленнән гомуми курсны тәмамлаган вакытта, укыту-тәрбия процессының яңа һәм мөһим элементы булып баланың мәктәптә теге яки бу төркемдә укуга (башлангыч мәктәптә телне туган тел буларак яки дәүләт теле буларак өйрәнү) функциональ хәзерлеген билгеләү санала. Баланың телне белү дәрәҗәсен ачыклау ата-аналардан интервью алу (анкета үткәрү), балаларны уен, махсус тудырылган аралашу ситуациясендә күзәтү кебек башкарыла.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында балаларга татар әдәбиятыннан белем һәм тәрбия бирү эчтәлегенең төп компонентлары булып татар балалар әдәбияты, туган як мәдәнияте белән таныштыру; үзенең нинди милләт вәкиле булуы, җирле табигый, географик, социомәдәни һ.б. үзенчәлекләр турында күзаллау формалаштыру; халык иҗатына (халык авыз иҗаты, музыкаль фольклор, халык декоратив-гамәли сәнгате һ.б.) якынайту торырга тиеш. Бу этапта татар әдәбияты сөйләм үстерү дәресләренең, шулай ук төрле: белем бирү, уен, иҗат һ.б. эшчәнлекләрнең – аерылгысыз өлешен тәшкил итә.

Татар әдәбиятыннан мәктәпкәчә белем бирү программасы әдәби текстларның эчтәлегенә уңай эмоциональ мөнәсәбәт формалаштыруны; элементар төшенчәләр хакында (фольклор һәм матур әдәбият, әдәби әсәрнең авторы, халык авыз иҗатының кайбер жанрлары, тезмә һәм чәчмә сөйләм) күзаллау булдыруны; әңгәмә алып бару күнекмәләре формалаштыруны (сөйләшүгә катнашу, үз фикерен белдерү, сораулар һәм аларга җавап бирүне, әңгәмәдәшкә хөрмәт белән карауны, фикерләүдә мөстәкыйльлекне) тәэмин итәргә тиеш.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында татар теле һәм татар әдәбияты буенча укыту һәм тәрбия эшен уңышлы тормышка ашыру яңа педагогик тенденцияләрне, мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту методикаларын, һәм шулай ук баланың кабул итү, хәтер үзенчәлекләрен исәпкә алып, татар теле һәм татар әдәбиятыннан

заманча, нәтиҗәле, сыйфатлы бизәлешле укыту-методик комплектлары, аудио-видеоматериаллар, мультимедиа әсбаплары эшләү һәм чыгаруны күздә тота.

## 5.4. Башлангыч гомуми белем бирү

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында татар телен туган тел буларак укыту программасы билгеләнгән минимумга туры китереп сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен (тыңлау, уку, сөйләү, язу) үзләштерүне; балага гражданлык үзбилгеләнүенең нигезләрен, үзенең нинди этник төркемгә каравын төшендерүне; лингвистик фикерләүне киңәйтү, тел берәмлекләре ярдәмендә аралашу, шәхескә кагылышлы, танып белү, коммуникатив һәм регулятив универсаль уку гамәлләрен алга таба формалаштыру өчен нигез булып хезмәт итәчәк татар теленең системасы һәм структурасы турында беренчел күзаллаулар булдыруны тәэмин итәргә тиеш.

Бу баскычта татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү нәтиҗәсендә укучыларда элементар чит телдәге кебек аралашу компетенциясен формалаштыру, ягъни түбән сыйныф укучысының сөйләм мөмкинлекләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып, телдән (сөйләү һәм аудирование) һәм язмача (уку һәм язу) формаларда татар телле әңгәмәдәшләре белән аралашырга сәләтле һәм әзер булуларына ирешү; өйрәнелә торган телнең төзелеше һәм аның туган телдән кайбер аермалары турында гомуми күзаллау булдыру; коммуникатив мәдәниятлелек нигезләрен, ягъни аралашырга өйрәтү, аралашуның сөйләмә һәм сөйләмә булмаган чараларын дөрес куллану, сөйләм этикетын саклау, әдәпле һәм матур сөйләмле әңгәмәдәш булу сәләтләрен үстерү шарт.

Гомуми белем бирүнең башлангыч этабында татар әдәбияты «Әдәби уку» предметы буларак укытыла. Әдәби уку чаралары ярдәмендә тормышка ашырыла торган төп максат – эстетик зәвыклы, әдәби әсәрне аңларга сәләтле, үз карашын дәлилле һәм аны төрле жанрда телдән һәм язмача әйтеп бирә алучы, аналитик һәм шәрехләү төсендәге фикерләр формалаштыра белгән, укылган буенча сөйләшүдә катнаша алган грамоталы китап укучы тәрбияләү.

Башлангыч мәктәптә туган телдәге әдәбият буларак татар әдәбияты курсы милли мәдәнияткә кызыксыну һәм игътибар формалаштырырга, әдәби текстларны кабул итү күнекмәләрен ныгытырга тиеш. Шуңа ярашлы рәвештә татар әдәбиятын туган телле әдәбият буларак өйрәнгән сыйныфларда әдәби уку программалары фольклор әсәрләренең һәм авторлык әдәбиятының төрле жанрларын бәяләү өчен кирәк булачак нигез төшенчәләр формалаштыруны; текстны укый, аңлатып бирә, анализ ясый һәм шәрехли белүне; әсәрдәге сюжет сызыкларын аера алуны; төрле карашларны яки позицияләрне күрә белүне; текстның төп фикерен билгеләүне; текстны һәм аның өлешләрен анализлауны

(сораулар һәм биремнәр системасы аша); укылганга шәхси бәя бирә һәм мөстәкыйль фикер йөртә алуны күздә тота.

Татар әдәбиятын чит телдәге әдәбият буларак өйрәнә торган төркемнәрдә әдәби уку программалары әдәби текстны укый һәм эчтәлеген сөйли белүне эзлекле формалаштыра; сәнгатьлелек чараларын ачыкларга өйрәтә; геройның характерын күзаллауны, төрле геройларның тәртибен чагыштырма планда тикшерүне; сөйләмне ишетеп кабул итү, эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү, тыңланганның эчтәлеге буенча сораулар бирә белүне, вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләүне; зур булмаган текстны мөстәкыйль укый белүне; сөйләшеп аралашуны; хат һәм кечкенә диктантлар язуны тәэмин итә.

## 5.5. Төп гомуми белем бирү

Татар телен туган тел буларак укытуның төп гомуми белем бирү программасы укытуның метапредмет һәм предмет нәтиҗәләренә ирешүне максат итеп куя, компетентлыклы нигездә, аралашу, лингвистик, этномәдәни компетенцияләр формалаштыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән һәм билгеләнгән минимумга туры китереп сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен (тыңлау, уку, сөйләү, язу), телдән һәм язма сөйләм культурасы нигезләрен, әлеге укучылар өчен тормышта мөһим булган күләмдә аралашу һәм телне куллануның төп кагыйдәләрен һәм күнекмәләрен үзләштерүне; дөрес һәм грамоталы аралашу өчен тел материалының төзелеше, структурасы һәм эчтәлеге турында теоретик мәгълүматлар булдыруны; гомумевропа тел портфолиосы методикасы белән таныштыруны; татар теленә милли мәдәниятне, халыкның теле, әдәбияты һәм тарихы үзара бәйләнешен чагылдыру формасы итеп карауны; милли тел берәмлекләре турында белемнәрне, татар сөйләм этикетын һәм милләтара аралашу культурасын үзләштерүне; татар әдәби сөйләме нормаларын белүне, алар аша халыкның милли-мәдәни үзенчәлекләрен аңлауны тәэмин итә.

Татар телен дәүләт теле буларак укыту төп гомуми белем бирү программасында билгеләнгән минимумга туры китереп сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен (тыңлау, уку, сөйләү, язу) үзләштерүне; укучыларда сөйләм, тел һәм социомәдәни компетенцияләрне үстерүне; татар теле нормаларын гамәли үзләштерүне; татар теленең татар әдәбияты, мәдәнияте һәм тарихы белән бәйләнешен аңлауны алга куя.

«Татар теле» предметыннан бердәм тест уздыру үз эченә язма сөйләмне генә түгел, ә телдән сөйләмне үзләштерү дәрәҗәсен бәяләүне дә алырга тиеш.

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә татар әдәбиятын туган телдәге әдәбият буларак өйрәтү укучыларның иң камил әсәрләрне аңлауларын, аларны уку һәм әдәби форма-эчтәлек берлегенә таянып анализлауны; милли үзаң үсеше, үзбилгеләнү өчен шартлар тудыруны; татар халкының тарихы, мәдәнияте, дөньяга карашы, тормышны кабул итүе, менталитеты, фәлсәфәсе, теле турында системалы белемнәр булдыруны күздә тота.

Татар әдәбияты чит телдәге әдәбият буларак «Әдәби уку» предметы форматында өйрәнелә. Әлеге предмет укучыларны татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә якынайтуны, аның күренекле вәкилләренең иҗаты белән таныштыруны; укучыларда әдәби әсәрне кабул итү, аңлатып бирү күнекмәләрен формалаштыруны; башка халыкларга толерант һәм ихтирамлы мөнәсәбәтле күпмәдәниятле шәхес тәрбияләүне; рус һәм татар әдәбиятларын чагыштырма планда анализлау ысуллары ярдәмендә укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыруны; әдәби әсәрнең аерым фрагментларын татар теленнән рус теленә һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү күнекмәләрен үстерүне тәэмин итә.

## 5.6. Урта гомуми белем бирү

Татар телен туган тел буларак укытуның урта гомуми белем бирү программасы компетентлыклы нигездә төзелә һәм аралашу, лингвистик һәм этномәдәни компетенцияләрне камилләштерүгә юнәлдерелә, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үстерүне тәэмин итәргә тиеш. Эчтәлек ягыннан ул үз эченә тормышта мөһим булган күләмдә һәм аралашу ситуацияләрендә телне дөрес һәм ирекле куллану осталыгын һәм күнекмәләрен, татар әдәби теленең нормаларын белүне, сөйләм этикетын, сәнгатьле сурәтләү чараларын, шулай ук телнең төрле функциональ чараларын куллануны үз эченә ала. Бу аралашу мөмкинлекләрен (коммуникатив мотивацияне) үстерүне, барлык тел берәмлекләренең мәгънәләренә һәм вазифаларына аерым игътибар бирүне күздә тота.

Татар телен дәүләт теле буларак укытуның урта гомуми белем бирү программасы билгеләнгән минимумга туры китереп сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен (тыңлау, уку, сөйләү, язу) югары дәрәҗәдә үзләштерүне; укучыларда сөйләм, тел һәм социомәдәни компетенцияләрне үстерүне; төрле телләрдә һәм мәдәниятләрдә уртак һәм үзенчәлекле сыйфатларны аңлау өчен татар теленең фонетик, лексик, грамматик һәм стилистик хасиятләре турында күзаллаулар булдыруны күздә тота.

Югары сыйнфыларда татар әдәбиятын туган телдәге әдәбият һәм чит телдәге әдәбият буларак укыту программасы борынгы заманнардан бүгенге көнгә кадәр милли әдәбиятның үсеш юллары турында тулы һәм системалы караш формалаштыруга юнәлдерелгән. Шуңа ярашлы рәвештә туган телле әдәбият буларак татар әдәбияты предметы милли әдәбият тарихын, аның аерым үсеш баскычларындагы төп үзенчәлекләренә басым ясап, өзлексез барыш итеп өйрәнүне; татар халкының мәдәни кыйммәтләрен аңлы үзләштерү нигезендә әхлакый-эстетик позиция, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыруны; күренекле шагыйрьләрнең һәм язучыларның иҗатларындагы яңалыкны һәм традицияләр дәвамчанлыгын аңларга күнектерүне күздә тота.

Татар әдәбиятын чит телдәге әдәбият буларак өйрәтү укучыларны татар мәдәнияте, татар әдәбиятының тарихы, аның күренекле вәкилләренең тормышы-эшчәнлеге һәм иҗаты турында материаллар белән таныштыруны; толерант фикерләү һәм үз-үзен тотыш тәрбияләүне; төрле темаларга татар телендә ирекле сөйләшү сәләтләрен үстерүне; татар халкы һәм башка халыклар мәдәниятен

үзләштерү ысулы буларак укуга тотрыклы кызыксынуны, аларга ихтирамлы мөнәсәбәтне үстерүне үз эченә ала.

### 5.7. Өстәмә белем бирү

Тел, әдәбият, туган якны өйрәнү, шигърият яратучылар клублары, түгәрәкләр, секцияләрне колачлаган өстәмә белем бирү системасы филологик белем бирүнең мөһим өлеше булып тора. Ул яшь буынның иҗади сәләтләрен, шәхси сыйфатларын һәм талантын ачарга, үстерергә тиеш.

Татар филологиясеннән өстәмә белем бирү системасын булдыруда әдәби яки туган якны өйрәнү музейлары, театрлар, һәйкәлләр, әдәби кичәләргә, күргәзмәләргә йөрү, экскурсияләр, ярышлар үткәрү, иҗади конкурслар һәм бәхәс клублары оештыру зур роль уйный.

Аерым игътибарны якшәмбе мәктәпләренә һәм җәйге лагерьларга бирергә кирәк. Алар өчен татар телен туган тел буларак өйрәнүнең төрле дәрәҗәләре һәм татар әдәбиятын һәм мәдәниятен өйрәнү буенча модульле программалар эшләү таләп ителә. Якшәмбе мәктәпләре һәм җәйге лагерьлар өчен татар теле һәм татар әдәбиятыннан төрле яшь категорияләре өчен уку әсбаплары әзерләнергә тиеш.

### 5.8. Урта һөнәри һәм югары белем бирү. Кадрлар әзерләү

Татар теле һәм татар әдәбиятын урта махсус белем бирү системасында укыту урта гомуми белем бирүнең әзерлек һәм белгечлек юнәлешенә бәйле адаптацияләнгән программаларына таяна. Шуңа өстәмә булып теге яки бу юнәлеш буенча белгечләрне укыту өчен махсус программалар әзерләнергә тиеш.

Һөнәри филологик белем бирү үз эченә түбәндәге дәрәҗәләрне ала: урта һөнәри белем бирү, югары белем (бакалавриат, специалитет, магистратура, аспирантура).

Һөнәри белем бирү этабында булачак белгечнең социаль мөнәсәбәтләрнең төрле сфераларында эшчәнлеге һәм башка этномәдәни төркемнәрнең вәкилләре белән аңлашуга һәм хезмәттәшлеккә сәләтлелеге белән бәйле этномәдәни тел компетентлыгын формалаштыру бурычы билгеләнә. Татар телен һәм татар әдәбиятын укытуның төп максаты булып татар тел белеме һәм әдәбият белеменнән гыйлемнәрен тирәнәйтү юлы белән квалификацияле кадрлар әзерләү тора.

Россия Федерациясендә татар филологиясе өлкәсендә эшләү өчен кадрлар әзерләүнең оештыру һәм методик аспектлары бар.

Россия Федерациясенең Мәгариф турындагы Законына (№273-ФЗ, 29.10.2012 ел) үзгәрешләр керү сәбәпле, мәктәпкәчә белем бирү алга таба башлангыч белем өчен нигез булып хезмәт иткән циклның беренче этабы санала. Шуңа күрә хәзерге көндә Татарстан Республикасында татар телен белгән мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү педагог-хезмәткәрләренә ихтыяҗ артты. Моңа бәйле рәвештә Россия Федерациясенең югары уку йорларында «Педагогик белем. Туган (татар) тел, әдәбият һәм мәктәпкәчә белем бирү»; «Туган (татар) тел,

әдәбият һәм башлангыч белем бирү» юнәлешләрендә катнаш программалар нигезендә укытуны киңәйтергә кирәк.

Татар теле һәм татар әдәбияты укытучыларының һөнәри дәрәҗәсен камилләштерү максаты белән:

татар балаларын татар теленә өйрәтүне тулысынча колачлап алу максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең татарлар компактлы яшәгән регионнарының белем бирү оешмалары өчен татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ихтыяҗны исәпкә алу методикаларын яңарту;

татар теле һәм татар әдәбияты укытучыларын хәзерләү һәм яңадан хәзерләү, шулай ук аттестацияләү (шул исәптән заманча мәгълүмати-коммуникатив технологияләрне дистанцион форматта куллану) мәсьәләләрен хәл итүдә җитди чаралар күрү;

татар теле һәм татар әдәбияты укытучыларына күптелле мохиттә укыту һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балалар белән эшләү өчен кирәк булган компетенцияләр формалаштыру өчен өстәмә һөнәри белем бирү системасын камилләштерү таләп ителә.

Алда әйтелгәннәр нигезендә, «Филология» һәм «Педагогик белем» юнәлешләрендә белгечләр әзерләүгә ел саен бюджет урыннарының кыскаруын, һәм Россия Федерациясендә филолог-галимнәрне, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын, татар балалары белән эшләү өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләрен һәм башлангыч сыйныф укытучыларын әзерләү оешмалары һәм структураларын оптимизацияләүне исәпкә алып проблеманы өйрәнү һәм 2030 елга кадәр тиешле юл картасын эшләү сорала.

## VI. Концепцияне тормышка ашыру

Бу Концепцияне тормышка ашыру Россия Федерациясе территориясендә татар әдәби телен саклауны һәм үсешен тәэмин итәчәк, Татарстан Республикасы дәүләт телләрнең берсе буларак татар теленең кулланылышын, татар телен һәм татар әдәбиятын өйрәнүне һәм укытуны яңа баскычка күтәрәчәк, һәм шулай ук Россиядә филологик белем бирүнең үсеш механизмнарын эшләү, сынап карау, гамәлгә кертүгә ярдәм итәчәк.

Концепцияне уңышлы тормышка ашыру өчен түбәндәге юнәлешләрдә аны гамәлгә кертү һәм фәнни ярдәм системасын булдырырга кирәк:

татар телен һәм татар әдәбиятын укыту практикасына яңача якын килү;

кадрлар әзерләү, аларның белемнәрен күтәрү һәм яңадан укыту;

Концепциядә язылган концептуаль мәсьәләләр буенча диссертацион һәм монографик тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен файдалану;

лингводидактика һәм әдәбият белеме мәсьәләләре буенча төп фәнни-гамәли чараларда кабул ителгән карарларны исәпкә алу.

Бу Концепцияне тормышка ашыруның механизмы булып тиешле бурычларны федераль һәм региональ программаларга һәм аерым белем бирү

оешмаларының федераль, региональ һәм муниципаль бюджет исәбенә финанслана торган үсеш программаларына кертү тора.